СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.54, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Чехов ур., 54 нче йорт, Югары Ослан авылы, 422570

РЕШЕНИЕ КАРАР

28.11.2024 с. Верхний Услон № 46-285

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Киров исемендәге поселок халкының инициативасын карап

Татарстан республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Киров исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 11 декабренә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2025 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Киров исемендәге поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрүгә сез ризамы?:

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Киров мәдәният йортында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Киров ис. поселок, Үзәк ур., 15 йорт, 17 сәгать 30 мин.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы Е.А.Варакин